**ГЛАВА**
**Крындинского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кырынды авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2020 Кырынды авылы. № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тукай торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тукай торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2020 елның 19 ноябрендә 11 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» Тукай торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Тукай авыл кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы авария хәлендәге һәм корыган үсентеләрне кистерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Тукай авылында, Тукай урамы, 17нчейорт адресы буенча фельдшерлык-акушерлык пункты территориясендә уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы И. И. Закиров